**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы**
**Куакбаш авыл җирлегенең**
**Куакбаш торак пункты гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2024 елның 1 апреле № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш торак пунктында гражданнар Җыенының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында»2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (29.11.2023 №1532 редакциясендә) карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән,Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, 2024 елның 1 апрелендәге «Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карары һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү турында 2024 елның 1 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбашторак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы һәм «Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Совет урамы, Ленин урамы, М. Җәлил урамы, Х. Такташ урамы, К. Маркс урамы, Маяковский урамы, Тукай урамы, Сәйдәшев урамы, Г. Исхакый урамы, Яшьләр урамы));

2) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Куакбаш авылында янгын сүндерү машинасы өчен җылы боксны җылыту)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, К.Маркс ур., 15; Сходнево-Чертанлы авылы - Ирек ур., 5б йорт, авыл мәдәният йорты бинасы; Чүте авылы - Тынычлык урамы, 8а йорт, авыл клубы бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә

һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова